МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.08.2026 Казан ш № 606

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ хокук бозу турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларының Исемлеген раслау хакында

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 8.1 статьясындагы $11^2$ һәм 16 өлешләре нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ хокук бозу турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларының кушымтада бирелә торган Исемлеген расларга.
2. Әлеге боерык 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.08.2026 № 606 боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ хокук бозу турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары Исемлеге

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 8.1 статьясындагы $11^2$ өлеше нигезендә административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 2.24 статьясында каралган административ хокук бозу турында беркетмәләрне Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының түбәндәге вазыйфаи затлары төзергә хокуклы:

махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының социаль гарантияләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләрен күзәтүче министр урынбасары;

махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының социаль гарантияләрен гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы;

махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының социаль гарантияләрен гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының социаль гарантияләрен гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәүче консультанты;

махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының социаль гарантияләрен гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы белгече.